КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 26 декабрь г.Казань № 1417

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен махсус икътисадый зоналарның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 29 сентябрь, 924 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 13 август, 818 нче, 2022 ел, 20 октябрь, 1116 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен махсус икътисадый зоналарның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

9 пунктның икенче абзацында «30 календарь көннән иртәрәк» сүзләрен «10 календарь көннән иртәрәк» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү чыгымнарын каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 3 ноябрь, 1041 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 17 декабрь, 1246 нчы, 2022 ел, 02 август, 749 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү чыгымнарын каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.8. Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 эш көнендә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

2.2 пунктның икенче абзацында «30 календарь көннән иртәрәк» сүзләрен «10 календарь көннән иртәрәк» сүзләренә алмаштырырга;

3.8 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Килешүдә Ниятләр турындагы килешүдә билгеләнгән төгәл датасы һәм субсидия бирү нәтиҗәләренең ахыргы мәгънәсе (нәтиҗәләрнең төгәл сан характеристикасы) каралган.»

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин